КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 15 февраль г.Казань № 89

М.Җәлил исемендәге республика
премиясен бирү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге республика премиясе турында» 1997 ел, 27 февраль, 175 нче карары, М.Җәлил исемендәге республика премиясен бирү комитеты утырышының беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елда М.Җәлил исемендәге республика премиясен бирү комитеты тарафыннан игълан ителгән конкурс нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләргә М.Җәлил исемендәге дүрт республика премиясен бирергә:

Татар әдәбиятын үстерүгә өлеш керткән, «Бөртекләп җыелган гомер» китабын иҗат иткән һәм «Күңелгә илһам килә» җыентыгында шигырьләр тезмәсе бастырып чыгарган өчен Дания Нурулла кызы Галәветдиновага;

театр сәнгатен үстерүгә, балалар һәм яшьләр өчен татар театрын саклап калуга һәм популярлаштыруга зур өлеш керткән өчен Булат Илдар улы Гатауллинга;

театр сәнгатен үстерүгә, балалар һәм яшьләр өчен татар театрын саклап калуга һәм популярлаштыруга зур өлеш керткән өчен Айвар Нурис улы Гыймаевка;

музыка сәнгате өлкәсендә ирешкән уңышлар өчен Зөлфәт Тәлгать улы Фәхразыевка.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин